Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLII-7**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 26сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2023 елның 25 маендагы XXXVIII-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 мартындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2023 елның 25 маендагы XXXVIII-10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 19.3 пунктының 2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад яисә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 маддәсе нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан;»;

1.1) 6.5 пунктчасын «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан гайре.» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2) 6.7 пунктчасын «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан гайре.» сүзләре белән тулыландырырга;

1.3) 7.7 пунктчасында «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан гайре.» сүзләре белән тулыландырырга;

1.4) 7.7 пунктында түбәндәге эчтәлектәге 7.7.1 пунктчаны өстәргә:

«7.7.1. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан 7.7 пунктчасында күрсәтелгән

дөрес булмаган мәгълүматны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.1) муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын (каршылыгын, низагын) булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм чикләүләрне һәм тыюларны коррупциягә каршы тору максатында үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 13 маддәсенең 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар тикшерүе тарафыннан танылa икән.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов